**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2023елның 10 ноябре** **10790/исх номер**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар башлану турында белдерү.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 февралендәге 96-РС номерлы үзгәрешләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектыбуенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2023 елның 8 ноябрендәге 122-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары белән, тормышның уңай шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты хәбәр итә:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар 2023 елның 15 ноябреннән 2023 елның 15 декабренә кадәр үткәрү турында.

Проектның мәгълүмати материаллары:

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;
- җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;
- җирлекнең функциональ зоналары картасы.

җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге.

- Генераль планны нигезләү материаллары

2. Чирпы авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш

объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар дип танылa.

Проект экспозициясе Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең рәсми сайтында https://laishevo.tatarstan.ru/ekspozitsiya-proektov-generalnih-planov.htm веб - адресы буенча, «Чирпы авыл җирлеге» бүлегендә ачык булачак, шулай ук Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Чернышевский ур., 23 адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында киңәшмәләр залында. Проект материаллары белән Интернет мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең рәсми сайтында https://laishevo.tatarstan.ru/ekspozitsiya-proektov-generalnih-planov.htm веб – адресы буенча экспозициянең бөтен вакыты дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында проект белән 2023 елның 23 ноябреннән 2023 елның 29 ноябренә кадәр 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин .

4. Ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары уздырылачак:

Чирпы авылында 2023 елның 6 декабрендә 10:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: _Чирпы авылы, Завод урамы, 22 йорт - башкарма комитет бинасы;

- Имәнкискә авылында 2023 елның 6 декабрендә 11:30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Имәнкискә авылы, Совет урамы, 22а йорты - Мәдәният йорты бинасы;

- Мирәтәк авылында 2023 елның 6 декабрендә 13:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Мирәтәк авылы, Интернационал урамы, 3 йорт янында.;

5. 3 пунктта күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар түбәндәге тәртиптә проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар оештыручы адресына: Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһ., Чернышевский ур., 23;.

- Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһ., Чернышевский ур., 23; адресы буенча проект экспозициясенә килүчеләрне китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән.

Шулай ук проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын уздыру барышында язма яисә телдән тапшырылырга мөмкин.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып. Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокук ияләре булган гавами

тыңлауларда катнашучылар шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, биналар турында белешмәләр, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга аларның хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Ачык тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз ризалыкларын бирәләр.

6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**